
Бүгенге санда:



Җылылык өчен яңача түләү кетелә. 2 бит

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Дружба

Җомга 14 август 2015 ел

№ 59 (10588)

**15 августка һава торышы:** аязучан болытлы һава, җил көнбатыштан, 3-5 м/с; температура көндез +18°С, төнлә +13°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### МӘКТӘПКӘ ҖЫЕНДЫРДЫЛАР

"Мәктәпкә җыенырга булыш!" республика хәйрия акциясе кысаларында район оешма-предприятие җитәкчеләре, эшмәкәрләр, иганәчеләр 39 балага ярдәм күрсәткәннәр. Аларга 117 мең сумлык мәктәп портфельләре, канцелярия товарлары, мәктәп һәм спорт формалары сатып алынган.

### ИГЪТИБАР, БАЛАЛАР!

15 августтан 15 сентябрьгә кадәр районда традицион "Игътибар, балалар!" профилактик акциясе уза. Бу чорда ЮХИДИ хезмәткәрләре балалар арасындагы юл травматизмын профилактикалауга корылган төрле чаралар оештырачак. Моннан тыш, ДПС хезмәткәрләре мәктәпкәчә белем бирү, мәгариф учреждениеләре янында кизү торачаклар, профилактик әңгәмәләр үткәрү дә планлаштырыла.

### АГИТБРИГАДА – КЫРДА


Район мәдәният хезмәткәрләреннән торган агитбригада район басу-кырлары буйлап чыгышларын дәвам итә. Бер атна эчендә алар "Нурлат сөте", "Южная", "Агромир", "Сөләйманов Ә.И" хуҗалыклары басуларында булып, урак батырларына иң матур җырларын һәм игенчене олылаган җылы сүзләрен бүләк итәргә өлгерделәр. Агитбригада үз чыгышларын алга таба да дәвам иттерәчәк.

### ӨЧ КӨН ЯЛ КӨТӘ

30 август – Республика көне якшәмбегә туры килү сәбәпле, Татарстанда дүшәмбе ял көне дип игълан ителә. Шулай итеп, август азагында өч көн – 29, 30, 31 август көннәрендә ял итәчәкбез.

**Газетаның электрон версиясен nurlat-tat.ru сайтында укыгыз**

# Яшьләр киләчәккә ышаныч белән карый



Лилия Мөбарәкшина фотосы

РАМИЛ КӘРИМОВ БЕЛӘН СЕРГЕЙ СЕЛЕЗНЕВ ЭШ УРЫНЫН ҮЗ ТУГАН ҖИРЛӘРЕНДӘ ТАПКАННАР

**Татарстан Франция һәм Бельгияне отып, WorldSkills Competetion үткәрү хокукын отты.**

2019нчы елда эшче һөнәрләр буенча WorldSkills чемпионаты Казанда үтәчәк. Дүшәмбе көнне Сан-Паулудагы WorldSkills International генассамблеясында халыкара жюри әгъзалары шундый карар кабул иттеләр. Татарстан делегациясен Республика лидеры Рөстәм Миннеханов җитәкләде. Үз территорияләрендә чемпионатны кабул итү өчен Париж һәм Шарлеруа шәһәрләре дә көрәште, әмма күпчелек жюри әгъзалары Казан өчен тавыш бирде.

Жюриның карарына Татарстанның халыкара дәрәҗәдәге спорт бәйгеләрен оештыру буенча уңай тәҗрибәсе дә йогынты ясагандыр, мөгаен. Өстәвенә, WorldSkills Казан өчен яңа нәрсә түгел. Татарстан башкаласы ике ел рәттән WorldSkills Russia милли чемпионатының суперфиналларын үзендә кабул итте. "Казан ярминкәсе" күргәзмәләр үзәгендә үткән суперфиналларда Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган столярлар, балта осталары, слесарь-сантехниклар, сылаучы-буяучылар, электриклар һәм башка бик күп һөнәр ияләре үз осталыкларын күрсәттеләр. Һәм ике чемпионатта да Татарстан яшьләре команда ярышында беренче урыннарны яулады.

WorldSkills эшче һөнәрләр халыкара чемпионаты – яшьләрнең һөнәри әзерлеген һәм осталыгын камилләштерүне максат иткән һәм сәнәгатьнең барлык юнәлешләрен колачлаучы мөһим вакыйга булудан тыш, дәүләт органнары һәм белем бирү учреждениеләре, сәнәгать һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләренең очрашу урыны да, биредә һөнәри осталык белән бәйле иң мөһим актуаль сораулар турында фикер алышулар уза. Ә болар бүгенге Татарстан өчен аеруча актуаль, чөнки эшче һөнәрләрнең дәрәҗәсен күтәрү турыдан-туры икътисадның үсеше белән бәйле, ә бу республика җитәкчелеге һәм аның Лидеры Рөстәм Миннеханов үз алдына куйган иң өстенлекле бурычларның берсе. Республикада эшче һөнәрләрне популярлаштыруга юнәлтелгән төрледән-төрле проектлар, максатчан программалар тормышка ашырыла. Һөнәри белем бирүче уку йортлары базаларында ресурс үзәкләре булдыру – шуларның берсе. Ресурс үзәкләре – республика җитәкчелегенең җирле сәнәгать предприятиеләре белән берлектә эшче һөнәрләрне популярлаштыру һәм үстерүгә юнәлтелгән уртак проекты. Узган елда Татарстанда шундый 5 үзәк барлыкка килде, быел тагы 5се үз ишекләрен ачачак. Республикада исә шундый 25 заманча ресурс үзәге булдыру күздә тотыла, аларның берсе шәһәребездә "Агро-Инвест" идарәче компаниясе һәм Нурлат аграр техникумы базасында булачак. Димәк, ресурс үзәге турыдан-туры "Агро-Инвест"ның шикәр заводы, элеваторы һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре өчен югары квалификацияле һөнәр ияләре әзерли башлаячак.

– Ресурс үзәге безнең предприятие өчен яшь кадрлар туплау ягыннан бик зур мөмкинлекләр ачачак, - дип саный "Нурлат шикәре" җәмгыяте генераль директоры Игорь Сагайдак. – Заводка югары квалификацияле кадрлар һәрчак кирәк. Үзәк исә җирле яшь кадрлар белән тәэмин итү ягыннан да отышлы булачак.

*(Ахыры 2нче биттә)*

АКТУАЛЬ

# Сынау мөмкинлеге бирелә

**Сентябрь-октябрь айларында укучылар бердәм дәүләт имтиханын кабат тапшыра алачак.**

Быелдан гамәлгә кергән үзгәрешләр чыгарылышларга мәҗбүри фәннәр буенча тагын бер тапкыр үзләрен сынау мөмкинлеге бирә. Урта гомумбелем бирү программасы буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибенә кертелгән үзгәрешләр нигезендә, агымдагы елның көзендә имтиханны БДИга җитди сәбәпләр аркасында килә һәм ике мәҗбүри фән буенча да минималь баллны туплый алмаган яки өстәмә вакытта тапшырып янә бер фәннән начар нәтиҗә күрсәткән, шулай ук математика һәм рус теленнән балларны яхшыртырга теләгән узган елгы чыгарылыш сыйныф укучылары тапшыра ала.

Яңалыклар хакында БДИ буенча координатор Неля Гыйззәтуллина менә нәрсәләр сөйләде.

- Укучыларга ел дәвамында берничә тапкыр БДИ тапшыру мөмкинлеге бирү турында инде узган елда ук сүз чыккан иде, - ди Неля Владимировна. - Моның өчен махсус үзәкләр челтәре ачылачак. Көзен имтихан тапшырырга теләгән укучыларга гариза бирергә кирәк булачак. Гаризаларны 25 августтан 12 сентябрьгәчә чыгарылышлар үзләре белем алган мәктәпләргә тапшырырга тиешләр.

**Зилия ӘКСАНОВА**

МӘГЪЛҮМАТ

**Өстәмә имтихан бирү көннәре:**
**26 сентябрь – математика (база өлеше), математика (профиль өлеше);**
**29 сентябрь – рус теле;**
**9 октябрь – математика (база), математика (профиль), рус теле.**

# ВАКЫТ. ВАКЫЙГА

УРАК ӨСТЕ

## Аларны урак дуслаштырган



ХУҖАЛЫКНЫҢ ЯШЬЛӘР ЭКИПАЖЫ

**“ИРС” хуҗалыгында урып-җыюның иң кызган мәле – шул көннәрдә механизаторлар уҗым культураларын җыюны төгәлләп, экватор чиген уздылар.**

Хуҗалыкта уракта өч комбайн мәшгуль, һәм комбайнчыларның фамилияләрен атаганда һич тә ялгышырмын дип куркасы юк: һәр өчесенең дә штурвалы артында Петровлар һәм Хадысовлар утыра. Иң беренче булып уҗым бодае басуында эшләрне төгәлләп килүче Евгений Петров экипажы янында тукталдык. Яшь булса да, комбайны стажы кечкенә түгел – 5 еллап. Аңа кадәр исә 11 яшеннән әтисе янында комбайны ярдәмчесе булып эшләгән. Өченче ел рәттән уракка Юныс Хадысов белән чыгалар икән. Юныс Грозный шәһәрендә техник университетта белем ала, ел да каникулларында әтисе эшләгән Татарстан якларына килеп, уракта катнашырга да өлгерә. 19 яшендә генә булса да, тәҗрибәле кулдашы янәшәсендә рәхәтләнеп эшли, хуҗалыкның яшьләр экипажы тәҗрибәле комбайнчылардан һич тә калышырга җыенмый.

Тагы бер басуда Евгенийның әтисе, Петровлар династиясенең иң тәҗрибәле комбайнчысы Петр Георгиевич тырышып хезмәт куя булып чыкты, аның янәшәсендә – Юнысның абыйсы Йосыф Хадысов, ул да техник университет студенты. Петров-Хадысовларның икенче экипажының сабан бодае урдыруга күченгән чаклары иде. Ә менә хуҗалыкның өченче экипажын бары тик Петровлар гына иярли. Руль артында – шулай ук тәҗрибәле комбайнчы Викентий Георгиевич, басуга улы Павел белән чыкканнар быел. Әтисе янәшәсендә Петровларның тагы бер буыны техника серләренә өйрәнә шулай. Хуҗалыкта һәр өч комбайн экипажы өчен дә күңелләре тыныч, иртә таңнан караңгыга кадәр тырышып хезмәт куя комбайнчылар.

Кыр кораблары ышанычлы кулларда булса да, быелгы үзенчәлекле урак “ИРС”лыларга да җиңел бирелми. Әнә, ашлыкның сыйфатына хилафлык китермәс өчен, июль яңгырларыннан соң ямь-яшел булып киткән, тигез өлгермәгән басулардан игеннәрне аеры урдыру юлы белән алырга мәҗбүрләр.

– Башта Алексей Михайлов МТЗга тагылган ЖВП ярдәмендә игеннәрне теземнәргә салып чыга. Дүрт-биш көн киптергәннән соң гына комбайннар суктырырга керешә, - ди хуҗалык җитәкчесе вазифаларын башкаручы Магомет Хадысов. – Дөрес, болай эшләү чыгымлырак, каядыр 30 процентка артыграк чыга. Аның каравы, ындыр табагына игеннәр кибеп, күпкә сыйфатлырак булып кайта.


Хуҗалыкта быел урып-җыю мәйданнары 1385 гектар тәшкил итә, аның 535 гектарында уҗым культуралары, 450 гектарда арпа, 200шәр гектарда сабан бодае һәм солы үстергәннәр. Тагы 200ләп гектарда көнбагыш игәләр, кукурузлары бар. Быел уңыш көтелгәннән азрак булса да, аны вакытында җыеп, урнаштыруны максат итәләр “ИРС”лылар. Әнә, җыелган игеннең бер өлешен халыкка пай җирләре өчен өләшергә дә өлгергәннәр инде. Бер өлеше орлыкка, икенчесе хуҗалык терлекләренә азыкка, шуннан арткан сатуга китәчәк. Басулардагы саламда да шунда ук төргәкләргә салынып, терлекчелек бинаалары территориясенә кайтарыла.

Уракны төгәлләү сроклары турында сөйләргә әле иртәрәк булса да, комбайнчыларның кайсына гына сүз катма, барысының да җавабы һава торышына барып тоташа.

– Һава гына көйле торсын, үзебездән торганның барын да эшләячәкбез, - дип ышандыра “ИРС”лылар.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

**13 августка Район хуҗалыкларында урак башыннан бирле суктырылган иген, тонналарда.**




**Район буенча барлыгы 48042 тонна ашлык суктырылган. Кичәге көнгә барлык мәйданнарның 58 процентыннан (23569 гектар) игеннәр җыел алынган, уртача уңыш бер гектарга 20,4 центнер тәшкил итә.**

АБИТУРИЕНТ-2015




## Хыяллар чынга аша

**Бу көннәрдә Нурлат чыгарылышлары вузларга укырга керүләре турында сөенечле хәбәрләр ала башладылар.**

Шәһәрнең 1нче мәктәбе чыгарылышы Аэлита Хәйруллина да әлеге сөенечле хәбәрне иң элек әнисе Роза белән уртаклашкан.

– Беренче дулкында ук бюджет урыннарында үз фамилиямне исемлектә күрү – гомер буена истә калырлык вакыйга, – ди Аэлита бүген җиңел сулап. Аэлита - быелдан Мәскәүдәге Пирогов исемендәге Россия милли-тикшеренү медицина университетының педиатрия бүлеге студенты.

– 5нче сыйныфтан ук табиб булырга хыялландым, – ди кыз. – Рус теле, биология һәм химия фәннәреннән җәмгысе 249 балл җыйдым. Мәктәпне бары “5”ле билгеләренә генә тәмамлавым да ярап куйды. Моның өчен тагын 5 балл өстәлде. Шулай итеп, берьюлы Казан, Самара, Мәскәү һәм Санкт-Петербург вузларына документларымны тапшырдым. Һәм әле шул көннәрдә генә Самара, Санкт-Петербург һәм Мәскәү вузларына узуым турында хәбәр алдым. Документларны тапшырганда, оригиналын Мәскәүгә биргән идем.

Район мәгариф идарәсе җитәкчесе Линар Маняпов әйтүенчә, укырга кергәндә монысы да исәпкә алына икән.

– Әлеге система абитуриентларга үзләре теләгән вузны сайлауда ярдәм итә, – ди ул. – Һичшиксез, үз позитив яклары бар.

Алдагы еллардагы кебек үк, быел да чыгарылышлар 5 югары уку йортының 3әр факультетына гаризалар бирә алган. Аэлита – көчле абитуриентларның берсе. Ул үзе теләгән вузга керү өчен 6 ел үзлектән һәм репетиторларга да йөреп әзерләнгән. Мәктәптә укыганда ук сәнгать мәктәбен тәмамларга да өлгергән, бию белән шөгыльләнгән, инглиз телен тирәнтен өйрәнгән. Ә медицина юнәлешен сайлавын гаилә традицияләре белән бәйли. Әнисенең апасы РКБда табиб булып эшли икән.

Ә Мәскәүдә Аэлита сыйныфташы – нефть һәм газ юнәлешен сайлаган Светлана Ханова белән бергә яшәячәк. Киләчәктә тә язмышларын Мәскәү белән бәйләмәкчеләр.

...Вузларга керү кампаниясе төгәлләнде. Иң популяр һөнәрләр рейтингында быел да юрист һәм икътисадчы лидерлык итә, шулай ук медицина, техник, педагогика һәм чит телләрне өйрәнү белән бәйле юнәлешләр дә популяр булган.

Зилия **ӘКСАНОВА**

ИНФРАСТРУКТУРА

## Кече Камышлыга күпер һәм юл төзелә

**Кече камышлылар өчен күпер һәм мәктәпкә кадәр юл төзү күптән көтелгән шатлык булды.**

Бу проблеманың тарихы болайрак: буып куйган кичүне ел саен су баса, һәм аннан авылга керүе куркынычка әверелә иде. Ә юллар белән бәйле һәркемгә мәгълүм бәла турында сөйлисе дә юк. Хәзер Кече Камышлыдагы әлеге бәлаләрнең икесе дә хәл ителү ягында. Район башлыгы Равил Кузюровның булышлыгы белән федераль линия буенча средстволар бүлеп бирелгән, һәм эшләр тулы көченә бара.

Без килгән вакытта Кече Камышлыда “ПКиМ” төзелеш компаниясенең Әлмәт подразделениесе прорабы Исламгали Мостафин җитәкчелегендәге бригада эшли иде.

– Бүген биредә 10 кеше һәм 7 берәмлек техника мәшгуль. Без ике атналап эшлибез инде. Биредә 1,5 километрлы юл һәм мәктәп автобусы өчен борылу полосасы ясалачак, – диде Исламгали Мингалиевич.

– Мондый үзгәрешләргә барыбыз да шат, яңа күперебез булачак. Күз алдыгызга гына китерегез, бөтен авыл буйлап асфальт юл узачак бит. Авыл халкы бик канәгать, – дип билгеләп үтә Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы Надежда Баймяшкина.

Бүген исә биредә күптонналы техника гүли, эш дәвам итә, компетентлы белгечләрнең төгәл контроле астында туфрак юл яңа йөз ала. Тиздән тигез булып асфальт түшәлер, ә инде көзен балалар яңа күпердән һәм такыр юлдан мәктәпкә йөрерләр.

Валентина **ВАФИНА**



НАДЕЖДА БАЙМЯШКИНА ИСЛАМГАЛИ МОСТАФИН БЕЛӘН ПРОЕКТ ХАКЫНДА ФИКЕР АЛЫША

